ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АБАЛАЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
АБАЛАЧ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 28 ноябреннән № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Абалач авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Абалач авылында яшәү урыны буенча теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, I һәм II төркем инвалидларын һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын, тыл хезмәтчәннәрен, көндезге уку йортларын тәмамлаучыларны төшереп калдырырга, III төркем инвалидлары һәм күп балалы гаиләләргә, инвалид балаларның ата-аналарына (опекуннарына) – бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Абалач авылы зиратын һәм янәшәсендәге территорияне чистарту
- Абалач авылында юл полотносын каплау өчен вак таш сатып алу
- Абалач авылында юл эшләре өчен махсус техника хезмәтләре
- Абалач авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган ветераннарга мемориал фасадын ремонтлау

3. Абалач авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Ш. Исрафилов